

ISSN 0868-4545

Салават күпере





Кечкенә рәссам





Казаннан ерак-еракта,әнием туган якта,
чәчәкле кырларда йөрдем —
чәчәк кызларын күрдем.

Алсу Мингалимовага журналлар һәм газеталарда әледән-әле урын бирелә тора, үзенчәлекле иҗаты турында фикерләр ишетелә. Аның эшләрен киң дөньяга танылган рәссам Надир Әлмиев югары бәяли. «Вечерняя Казань» газетасы Алсуны «татар гимназиясеннән Надя Рушева» дип атады. «Красная звезда» аша Александр Бугай: « Аның исемен игътибарда тотыгыз. Казанда зур рәссам үсүе ихтимал,» — дигән уен әйтте. Беренче рәсемнәре «Салават күпере»ндә чыга башлаган кыз өчен без шатланабыз, ул һәрчак безнең күз уңыбызда.

Алсу быел 2 нче классны тәмамлады, әлегә сәнгать мәктәбенә йөрми. Рәсемнәрне ул тиз һәм күп ясый. 8 яшенә хәтле ясаган рәсемнәренең саны 1000гә җитәр. Моннан соң ясаган рәсемнәре 1000 нән артык булыр. Әлегә матбугатка аның 6-8 яшьләр арасында ясаган рәсемнәре тәкъдим ителә.



Рәсемне менә шулай гына ясарга да ярый.

© "Салават купере", 1998 ел



Сергей АНДРИАНОВ

Моцарт, Шопен һәм Динара



Курчак уйнарга яратмый икән ул. Курчаклар белән маташырга вакыты юк икән.

Менә сиңа мә! Бу дөньяда шушы кадәр яшәп, курчак яратмый торган кыз турында ишеткәнем дә юк иде. Хәер, минем бит әле тугыз яшендә опера язган кыз турында да ишеткәнем юк иде. Ә Динара көйләрне биш яшьлек чагында ук, әле бернинди нота белмәгән килеш чыгара башлаган. Зурлар ул чыгарган көйләрне тыңлап шаккатканнар. Бу кыз шуннан бирле музыка белән генә яши диярлек. Курчак уйнау кая, яшьтәшләре кебек көн саен мәктәпкә йөрергә дә җай чыгара алмый. Әледән-әле дәрәҗәле конкурсларда катнаша. «Мин — композитор» дигән халыкара конкурста җиңүче булган.

Аны Моцарт белән чагыштыралар. Ә Динара үзе Шопенны ярата. Моцарт белән Шопенның бик зур композитор икәнен кайберләрегез беләдер инде. Ә кайсыларыгыз соңрак белер. Менә кемнәр белән янәшә куялар бер татар кызының исемен!

Динарага хәзер ундүрт яшь. Унөч яшенә кадәр ул ике опера, ике балет, фортепиано өчен ике йөздән артык кечкенә әсәр язган. Бик зур, бик кыю хыялы — Вена опера театрында үз әсәрен кую.

Хәтерләп калыйк, үскәннәрем. Исеме — Динара. Фамилиясе — Мәҗитова. Торган җире — Белоруссиянең Лида шәһәре. Укуын, мөгаен, Санкт-Петербургта дәвам итәр. Ә аннары... Бәлки, Вена? Ә?!

Фирая Бәдретдин



Рәсемнәрдә:
Динара.
Конкурстан соң. Янәшәдә — остазы Виталий Родионов.

Роберт Әхмәтҗан язган китапларның кайберләре:


Егерменче яз	1958
Йолдызстан	1964
Кызыл усаклар	1966
Идел-йорт	1972
Сабыйлар хоры	1978
Хәтер елгасы	1980
Орчык җыры	1988
Җәяүле күбәләк	1990
Тургай тәрәзәсе	1995


Рәссам Фәрит Муллахмәт

Дускай!

Журналның урта битен иплəп кенə алып, кара сызыклар буенча кис, сары сызыклар буенча бөклə дə, килеп чыккан кисəклəрне, бит саннарына карап, китап итеп җый. Булгач-булгач чын китап булсын — уртасын ике урыннан төплəп тə куй.

«Салават күпере» китапханәсе





Улым соравы

— Тургай кайда?
Якындамы?
Күкнең җиденче
катындамы?
Кайсы болыт артында ул?
Болыт бураздаларына әллә
җыр чәчәме?
Шытып чыкса,
Нинди булыр җыр чәчәге?
Җыр чәчәге...



Зәңгәр тай

Тәрәзәдән карый малай —
Өйләр ут алганнар.
Күктә йолдызлар һәм утлар
бергә буталганнар.

— Әнкәй, мин дә чыгыйм әле,
урамда инде — ай!..
Кичке болында йөгереп
уйныйдыр зәңгәр тай!..

Кояшлы кырлар


Кояшлы кырлар җилендә
җилфердәгән чак иде.
Тургайлар ике иңемдә —
минем туган як инде!

Барган саен ачыла яңа
офык —
җирнең яшел сырты!
Җир — түгәрәк!
Аның җилкәсендә —
минем туган йортым!

Як-ягымда яшел арыш
килә әйлән-бәйлән!
Туган йортка кайтып
барыш, —
җир, син тизрәк әйлән!

Түшәмнән төшә үрмәкүч —
«юл җебе» сара бугай.
Инде тургай тәрәзәмдә
сөенче ала бугай!





Сандугач гөле


Сандугач гөле комачтай,—
алып тора күз явын!
Үскән җире — кара туфрак,—
каян алган буявын?!


Тау битендә кызыл җиләк
балланып пешә икән!
Пешкән җире төче туфрак,—
каян бал эчә икән?

Укып белдем: болар барсы
Кояштан күчә икән!

Ялгыз бака зары

Яшел күлдә җырлый бака:
— Җылы кумырык, җылы кумырык!
Чебен-черки йотар идем,
тотарга юк,
йотарга юк.
Баш очында зәңгәр болыт
күлгә көмеш чәчмәс микән?
Хәлең мөшкел чакларында
бер төнбоек дәшмәс икән!..





Акбай

Безнең Акбай и йөгерә,
И ята, тора, өрә.
Ник өрмәсен, йөгермәсен,—
Эт бит ул шуңа күрә!

Имеш, җилгә дә өрмәсен,
Имеш, Айга өрмәсен!?
Ул чагында, койрык тагып,
Эт булып та йөрмәсен!

Яз хәбәре

Кыш ак башын алып качты,—
Яз килде.
Тугайларга үрдәк белән
каз килде.
«Күп көттермәм, килеп җитәм
мин дә!» дип,
Яз патшасы Былбылдан
аваз килде.





Саф карашлы, серле СӘЙДӘШ

Салих Сәйдәшев 1900елда Казанда туа. Әти-әнисе вафатыннан соң ул олы апасының гаиләсендә тәрбияләнә. Аның беренче музыка укытучысы атаклы халык музыканты, «Тукай маршы»ның авторы Заһидулла Яруллин була.

Унбиш яшеннән үк Салих «Сәйяр» драма труппасының уен кораллары ансамблендә эшли башлый. Егерменче еллардан — татар театрында эшләү чоры. Шул еллар эчендә Сәйдәшев алтмышлап спектакль-тамашага көйләр яза. Алар арасында безгә аеруча билгелеләре: «Наемщик», «Галиябану», «Зәңгәр шәл», «Башмагым», «Кандыр буе», «Бишбүләк»...

Замандашларының истәлекләрендә Салих Сәйдәшев бик гади, тыйнак һәм әдәпле кеше буларак сурәтләнә. Дусларына карата аның иң яраткан сүзләре «бәгырь» һәм «жанкисәк» була. Композитор турында халык язучысы Әмирхан Еники болай яза: «Салих Сәйдәшев һәр яктан да матур, күркәм кеше иде. Ләкин мин аның бер сыйфатын — үзенә бикләнгән шәхес булуын да билгеләп үтәргә телим... Гомумән, сәнгать натуралары — сер...»

Серле, моңлы мәшһүр көйязарыбыз Салих Сәйдәшев 1954 елда Казанда вафат була.

Зөлфия Хәлимова




Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Әкият



Рәссам Рәшит ШАКИРОВ



○ Бу рәсемнәр кайсы әкиятләрне сурәтли?

○ Ул әкиятләрне кем язган?

○ Бу шагыйрьнең тагын нинди әкиятләрен беләсең?

Рафис ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН

Айсылу

Әтисе Гүзәлгә Айсылу исемле курчак алып кайтты.

— Иптәшләрең белән бергәләп уйнарсыз,— диде ул кызына.

Әй сөенде, әй шатланды да соң Гүзәл. Җитен чәчле, зәңгәр күзле курчагын кулыннан бер генә дә кулыннан төшермәде. Җайсызрак тотканда Айсылу:

— Ән-нә, ән-нәү-ү... — дип тавыш та бирә белә иде.

Бүген ял көне. Гүзәлне бакчага илтмәделәр. Ул сөенеп Айсылу белән уйный гына башлаган иде, урам яктан күрше кызы Рәйханәнең тавышы ишетелде.

— Гүзәл, әйдә, уйнарга!

Кыз тиз-тиз генә киенде дә урамга йөгерде. Айсылуның:

— Мине дә алып чык, бергә-бергә уйнарбыз,— дип ялварып карап калуын да күрмәмешкә салышты. — Әйемлә, синең белән үзем генә уйнаячакмын,— дип ашыгып ишекне япты. Чөнки Рәйханә: «Әйдә инде бергә уйныйк әле,— дип Айсылуга үренер кебек тоелды. Тора-бара Гүзәл курчагы турында тәмам онытты. Өйгә кергәч кенә янә хәтеренә төшерде, йөгереп килеп Айсылуын кулына алды. Чү! Ни булган аңа? Кулга алуга:

— Ән-нәү-ү, тимәү-ү! — дигән сыман ыңгыраштты да күзләрен йомды.

— Әни, әнием,— дип алгы бүлмәгә йөгереп керде Гүзәл. — Айсылу минем белән уйнарга теләми.

Әнисе сынап кызына карады.

— Әллә үпкәләттеңме үзен?

Гүзәл генә ни дияргә дә белмәде. Бары шунда гына әтисе әйткән сүзләрне исенә төшерде.

— Иптәшләрең белән бергәләп уйнарсыз...

Гүзәл курчагының чәченнән йомшак кына сыйпап алды:

— Син ачуланма инде, икенче тапкыр сине дә дусларым янына алып чыгармын...

Айсылу зәңгәр күк йөзе төсле күзләрен ачып җибәрде.



Рәссам Светлана ИБРАГИМОВА

Назимә ХӘСӘНШИНА

Биючә кыз

(Яраткан укучым Лилия Галиеваның оста биюенә сокланып)

Әйдә, бие, әйдә, бие,
Әйдә, бие, Лилия!
Өздереп баскан чагыңда,
Бар кеше: «Их-ма», дия...

Әтиең өйрәтте мәллә,
Әниең өйрәттеме? —
Биегәндә табаныңнан
Ут чыксын, дип әйттеме?

Лилия биегән чакта
Очкыннар оча кебек.
Буй-сыннары бигрәк килгән,
Кемнәр сокланмас күреп...

Кояш кебек йөзләре лә,
Кара төймә күзләре —
Кыйгач кара каш астында
Көлеп тора үзләре...

Оча-оча бөтерелә, —
Күктән төшкән җилмени!
Тешләре, тезелеп киткән,
Йолдызлар күк җемелди...

...Бик күп милләт биюләрен
Бии беләсең, иркәм.
Юк килмәгән җиркәйләрең —
Кемгә булырсың икән?

Аллар ал кебек булсын да
Гөлләр гөл кебек булсын.
Ирек сөйгән күңелләрең,
Гел шатлык белән тулсын...



Сәрвиназ хикәяләре

Әхсән БАЯН

Күзлексез булмый

Сәрвиназга өч яшь тулмаган иде әле. Мин аңа китаплар укыйм. Кайчак укыр алдыннан:

— Бар, күзлек алып кил, аннары укырмын, — димен.

Ул күзлекне алып килә.

Укыйбыз.

Бу хәл шактый еш кабатлана. Ниһаять, бервакыт: « Укыйк әле, дәү әти!» — дип, үзе бер китап алып килгәч, мин аңа:

— Гел-гел генә миңа укырга димәгән, хәзер үзең укып күрсәт инде,— димен.

Кызның җавабы шул:

— Мин күзлексез укый белмим бит,— ди ул.

Кече әти

Сәрвиназ, дәү әти булгач, кече әти дә була, дип уйлап, үз әтисенә «младший әти» дип эндәште.

Монысы шул — кече әти дигән сүз инде.

— Ничек инде «кече әти»? — дип сорадылар аннан.

— Дәү әтием дә бар, младший әтием дә бар, — дип җавап бирде Сәрвиназ.

Үсәсе килми

— Менә үсәрсең, мәктәпкә барырсың, — дип кызыктырабыз Сәрвиназны.

Ә ул:

— Минем үсәсем килми,— ди.

— Нишләп? Мәктәпкә барасың килми мени?

— Килә.

— Алайса, ник үсәсең килми?

— Мин үскәч, әти картая.



Баштваткыч — баш эшләткеч


Ринат НУРУЛЛИН

Җидегән чишмәләрдә нич йөзек?

Җиде елга җитәкләшеп
Бер дәрья булып ага.
Үрелгән җиде инештән
Бер толымдай һәр елга.

Һәр инешкә җиде чишмә
Коя көмеш суларын.
Һәр чишмәгә йөзек төшкән —
Санап бирче шуларны!

Чишү ысулы: Мәсьәләнең шартлары буенча җиде елгага җидешәр инеш коя. Димәк, инешләр саны 7 x 7 = 49. Чишмәләр саны 49 x 7 = 343 була. Җавап: 343 йөзек.



Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Сәләват күпере

9(102) - 1998

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГЪЛУМАТ ҺӘМ МАТБУГАТ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ 1990 елның март аеннан бирле чыга

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства информации и печати РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке.
Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары - җаваплы сәркатип
Фирая БӘДРЕТДИН

Бүлек мөхәррире
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта
Дамир ҖӘЛӘЛЕТДИНОВ рәсемнәре

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

Татарстан газета-журналлар нәшрияты. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Производствога бирелде 4.09.98 ел.
Басарга кул куелды 4.09.98 ел.
Кәгазь форматы 84x108 1/16.
Басма табак 1,5 (2,1).
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 17200 данә. Заказ Я-421.
Бәясе килешү буенча.

POINT®

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

Рашат НИЗАМИЕВ

Урман кошы

Бакчадагы җиләкләрне
Чукып-чукып киткәнсең.
Кызгылт чияләремнән дә
Бераз авыз иткәнсең.

Үпкәләмим, безнең өчен
Калганы да җитәрлек.
Ләкин талантыңа синең
Тәмам исең китәрлек!

Рәхмәт инде, «рәхмәт»еңне
Җырың белән кайтардың.
Таңнар саен сайрый-сайрый
Хәйран эшләр майтардың.

Сайрауларың һәр чәчәккә
Шифалы тәэсир итте,—
Һәммәсе дә бал кортларын
Үзенә әсир итте.

Җырың белән баеткансың
Чәчәкләрне нектарга.
Урманыңда насыйп булсын
Сиңа тыныч йокларга...

